**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Балигъ булмаган Миңнегулов Аяз Марат улын,
11.05.2006 елда туган, Менделеевск шәһәренең
«Камские зори» балалар һәм яшүсмерләр өчен
социаль приютына вакытлыча урнаштыру турында

Балигъ булмаган яшьтәге Миңнегулов Аяз Марат улының, 11.05.2006 елда туган, авыр тормыш хәлендә калуын исәпкә алып:

Балигъ булмаган баланың ата-аналары:

-әнисе Миңнегулова Зимфера Марсил кызы, улын тәрбияләү һәм матди яктан карау буенча ата-аналар бурычларын үтәүдән явыз ният белән читкә тайпыла, З.М.Миңнегулованың яшәү шартлары балигъ булмаган А.М.Миңнегулов өчен куркыныч тудыра (Актаныш район судының 2022 елның 21 мартындагы карары белән ата-ана хокуклары чикләнгән, 2022 елның 25 апрелендә үз көченә кергән).

- баланың әтисе, Сәфәргалиев Марат Миңнеәхмәтович, 11.10.2009 елда вафат булган. Аталык хокукы М.Сәфәргалиев үлгәннән соң 2020 елның 01 июнендәге 2-34/2020 номерлы Актаныш район суды карары белән расланган. Ата булуны билгеләү турындагы таныклык Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге тарафыннан, 2020 елның 26 августында бирелде.

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 121-123 маддәсе, 155.1 маддәсе, «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Торак кодексының 57 маддәсенә таянып, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Актаныш үзәк район хастаханәсе»ДАССО медицина тикшерүе узу өчен 2006 елда туган балигъ булмаган Миңнегулов Аяз Марат улын урнаштырырга.
2. 11.05.2006 елда туган, балигъ булмаган яшьтәге Миңнегулов Аяз Марат улын, вакытлыча Менделеевск шәһәренең «Камские зори» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютка урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче РА Ильясов